Бүгенге санда:



Район халкы Сабан туен бәйрәм итте. 2, 5 битләр

# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 10 июнь 2015 ел

№ 42 (10571)

11 июньгә һава торышы: болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көнбатыштан 3 м/с; температура көндез +16°С, төнлә +13°С

КОТЛАУ

## ХӨРМӘТЛЕ НУРЛАТЛЫЛАР!

**Сезнең барчагызны да 12 июнь – Россия көне белән тәбрик итәм.**

Бу Россия Федерациясенең дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителгән көн. Тарихыбызның яңа этабы әлеге истәлекле дата белән бәйле. Шул чор эчендә илебез гражданлык җәмгыятен төзүдәге демократик чикләрне, фидакарь хезмәтнең кадерен, тынычлык һәм татулык чикләрен билгели алды. Шул еллар дәвамында Россия һәм Татарстанда күп эшләр башкарылды. Без ышанычлы адымнар белән алга барабыз, районда һәм шәһәрдә халыкның тормышы яхшы якка үзгәрә. Нурлатлыларның гражданлык активлыгы үсә. Безнең һәркайсыбыз үз иле, республикасы, районы һәм шәһәре белән горурлана. Россиянең бөек тарихына кагылышлыбыз булу тойгысы киләчәктә үешкә йөз тоткан юлыбызда уңыш нигезе булып торсын иде.

Хөрмәтле нурлатлылар! Барчагызга да бәхет, сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек телим. Туган төбәгебез хакына куйган намуслы хезмәтегездә уңышлар насыйп булсын!

**Равил Кузюров,**
**Нурлат муниципаль районы башлыгы, "Бердәм Россия" партиясенең Нурлат бүлеге секретаре**

ФИКЕР

## УЛЬЯН КУНАКЛАРЫ БӘЙРӘМЕБЕЗНЕ ОШАТТЫ

**Сабантуй Нурлаттагы милли бәйрәмгә дуслык визиты белән килгән Ульян өлкәсенең Иске Кулатка делегациясендә дә матур тәэсирләр калды.**

– Бәйрәм атмосферасы һәм аның масштабы шаккатырды. Милли авыллар, театрлаштырылган мәйданнар, күңел ачу чаралары, ат чабышлары бик ошады. Сабантуй безне яңа идеяләргә рухландырды. Нурлат районы җитәкчелегенә безне бәйрәмгә чакыруы, кунакчыллыклары өчен рәхмәт сүзләре җиткерәбез, - дип уртаклашты Иске Кулатка шәһәр тибындагы поселогының спорт комитеты вәкиле Анатолий Григорьев.

Иске Кулатка район телевидениесе исә Сабантуйның матур мизгелләрен якташлары белән уртаклашу өчен төшерде. Мәдәният бүлеге делегатлары билгеләп узганча, визит 2016 елда Иске Кулаткада узачак VII Бөтенроссия Сабантуена әзерләнү өчен файдалы буласы. Икенче көнне алар Оренбургка эстафетаны кабул итәр өчен Бөтенроссия авыл Сабан туена юл алдылар.

13 июньдә исә Нурлат Татарстанны Иске Кулатка Сабан туенда тәкъдим итәчәк.

## Сабан туе гөрләп узды




Зилия Әксанова фотосы

МӘРТӘБӘЛЕ КУНАКЛАРНЫ ҺӘРКАЙДА ҖЫР-БИЮ, ИПИ-ТОЗ БЕЛӘН КАРШЫЛАДЫЛАР

**Узган шимбә көнне халык иртәдән үк Сабантуй мәйданына ашыкты. Бирердәге күңелле музыка, сәүдә рәтләре, шашлык исе халыкны үзенә тартты, иртән явып үткән яңгыр да бәйрәмгә комачауламады.**

Сабантуйның тантаналы өлешен район башлыгы Равил Кузюров ачып, нурлатлыларны, районыбыз кунакларын милли бәйрәм белән котлады. Равил Әфраимович нурлатлыларның бәйрәмне матур кәеф белән каршы алуын билгеләп үтте. Барлык язгы кыр эшләре вакытында һәм сыйфатлы башкарылган.

– Районыбыз игенчеләре республикада беренчеләрдән булып язгы кыр эшләрен тәмамладылар, - дип үз чыгышын рәхмәт сүзләреннән башлады Равил Әфраимович. – Уңышка ныклы нигез салынды. 50 мең гектарда сабан культуралары чәчелде. Чәчүлекләрне тиешле дәрәҗәдә эшкәртеп, терлек азыгы әзерләүгә тотындык. Башка еллардагы кебек үк агымдагы елда да мул уңышка өмет тотабыз. Милли бәйрәмебезне матур кәеф белән каршы алуыбызда мактаулы кунакларыбыз – авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренең өлеше зур. Нефть, мәгариф һәм медицина, сәнгать, төзелеш, транспорт предприятиеләренең уңышлары белән горурланабыз.

Сабан туе – ул иң беренче чиратта кыр батырларына дан җырлау форсаты. Традиция буенча, бәйрәмдә язгы кыр эшләренә йомгак ясап, иң яхшы аграрийларны хөрмәтләделәр. Әнә, бу бәйрәмдә дә авыл уңганнары мәйдан уртасына парад колоннасы белән чыктылар. Менә алар, районның авыл хуҗалыгы үсешенә зур өлеш керткән һәм язгы кыр эшләрендә югары җитештерү – икътисади күрсәткечләргә ирешкән алдынгылар: "Сөләйманов Ә.И." КФХсы башлыгы урынбасары Ирек Хәйдәрҗанов, механизатор Илдус Яруллин, сыер савучы Оксана Охотникова, баш агроном Марс Сафин, "Южная" агрофирмасы генераль директоры Әдһәм Гарифуллин, сыер савучы Ольга Короткина, механизатор Николай Казаков, "Нурлат сөте" җәмгыяте директоры Вәзир Сәгыйров, механизатор Хәлил Сәмәрханов, "Агро–Развитие Плюс" ААҖ генераль директоры Дмитрий Понин, механизатор Владимир Миронов, "Тулпар Агро" башкарма директоры Йосыф Әхмәтсафин, механизатор Ринат Шәйхетдинов, "ИРС" агрофирмасы директоры Сәет Магомет Куркаев, механизаторы Станислав Осипов, "Восток-зернопродукт-Биләр" җәмгыятеннән 2нче отряд начальнигы Рәшит Сафин, 4нче отряд механизаторы Хәлим Насыйров, "Космос" хуҗалыгы җитәкчесе Роланд Чахмахчев, механизатор Илдус Шаяхмәтов, крестьян-фермерлык хуҗалыгы җитәкчеләре Николай Шерников, Алмаз Шәйдуллин, "Колос" җитәкчесе Ирек Камалов һәм район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге җитәкчесе Фаил Ивандеев һәм башкалар. Район башлыгы бәйрәмдә уңганнарны ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Рәхмәт хатлары, район башлыгы һәм "Бердәм Россия" сәяси партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе Мактау грамоталары, кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләде, акчалата премияләр тапшырды. "Бердәм Россия" партиясенең Киекле авылы башлангыч бүлекчәсенә спорт инвентарьлары алу өчен сертификат та тапшырылды.

Район кураторы, ТР урман хуҗалыгы министры Алмас Нәзиров нурлатлыларны язгы кыр эшләре тәмамлану белән котлап, үз сәламен, Республика лидеры Рөстәм Миннехановның котлавын җиткерде. Милли бәйрәмебезнең кунаклары – ТР буенча баш федераль инспектор Ренат Тимерҗанов, РИТЭК ААҖ генераль директоры Николай Николаев, ТР Дәүләт Советы депутаты, "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы Илгиз Салихов һ.б.лар сәламнәр юлладылар. Быелгы бәйрәмдә туганлаш Җәйхан шәһәре кунаклары, төрек дусларыбыз, шәһәр мэры урынбасары Сәләхетдин Гуляр, OZALSAN авыл хуҗалыгы техникасын җитештерү компаниясе генераль директоры Озджан Озал да катнашты. Нурлатлыларны бәйрәм белән котлаган Сәләхетдин Гуляр һәм Озджан Озал милли бәйрәмебезгә чакырган һәм җылы кабул иткәне өчен район башлыгы Равил Кузюровка рәхмәт сүзләре җиткерделәр. – Уртак тарихыбыз, телебез һәм мәдәниятебез булган туганлашларыбызның милли бәйрәмендә катнашу – зур дәрәҗә, - диде Сәләхетдин Гуляр. – Милли бәйрәмдә үзебез өчен бик күп файдалы мәгълүмат тупладык. Сабан туе безнең мәдәниятебезне һәм гореф – гадәтләрне саклаучы бәйрәм. Туганлаш Нурлатның соңгы елларда үзгәрешләрен күреп сөенәбез.

(Ахыры 2нче биттә)

## Укучыларыбыз игътибарына!

Алда өч көн ял булу сәбәпле, газетабызның чираттагы саны киләсе чәршәмбе, 17 июньдә чыгачак.

**15 ИЮНЬНӘН 25ЕНӘ КАДӘР ҖӘЙГЕ ЗУР ПРИЗЛЫ ДЕКАДА!**

**15 июньнән район газетасына 2015 елның II яртыеллыгына язылу буенча призлы декада игълан ителә. Бу чорда газетага язылучылар зур призлар уйнатуда катнашачак. Безнең призлар фондында 20дән артык бүләк – көнкүреш техникасы, йорт текстиле, савыт-саба һ.б.лар бар. Акциягә кушылып, почтага һәм редакциянең реклама бүлегенә ашыгыгыз. Сезне "Дуслык" көтә!**

## БӘЙРӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

# Сабан туе гөрләп узды



Авыл хуҗалыгы алдынгыларын Равил Кузюров бүләкләде

*(Ахыры. Башы 1нче биттә)*

Күршеләр - Чирмешән һәм Самара өлкәсенең Чаллы Башы районнары башлыклары Фердинант Дәүләтшин, Валерий Князькин, ТР Дәүләт Советы депутатлары Илгиз Салихов, Шамил Янудин, Рәис Сөләйманов, Мөхәммәтвәли Хөснетдинов һәм башкалар бәйрәмнең хөрмәтле кунаклары булдылар. "Бары бердәм булып, хезмәт һәм ялны бергә алып барганда гына матур күрсәткечләргә ирешергә мөмкин. Ә бу яктан Нурлат республикада алдынгылар рәтендә", - диделәр бәйрәмдә катнашкан мәртәбәле кунаклар. Тантаналы өлештән соң Сабантуй кунаклары район башлыгы Равил Кузюров озатуында "Нурлатнефть" НГДУсы, "ТНГ-НурГИС, "ТатРИТЭКнефть", Нурлат бораулау эшләре предприятиесенең импровизацияләнгән шәһәрчекләрендә булдылар, икмәк-күмәч ризыклары күргәзмәсен карадылар. Һәр шәһәрчек үз һөнәрләренең асылын ачып бирде. Сабан туе районыбызда яшәүче барлык милләт халкының уртак бәйрәме икәнен тагын бер кат раслады. Бәйрәмдә катнашкан кунаклар районда яшәүче татар, рус, чуваш, көнчыгыш һәм таҗик авылларында булып, аларның көнкүрешләре, йолалары белән таныштылар. Бергәләшеп җыр-биюләрдә, уеннарда катнаштылар, милли тәм-томнардан авыз иттеләр. "Осталар шәһәрчеге" халык сәнгате һәм декоратив–гамәли иҗат, самавырлар һәм Сабантуй орнаментлары белән чиккән сөлгеләр күргәзмәләре, умартачылык продукцияләре дә бәйрәм кунакларында зур кызыксыну уятты.

Нурлатлылар бәйрәм көнне "Президент белән бергә" республика акциясенә кушылып, Сабан туенда "Спортивный Татарстан" дигән үз мәйданнарын булдырдылар. Шәһәрләр һәм бәйрәм кунаклары хәрәкәткә кушылып, үз көчләрен ГТО нормаларын үтәүдә сынап карадылар. Район башлыгы Равил Кузюров та 40 тапкыр отжимание ясап, үзенең бер дигән физик формада булуын күрсәтте. Оештыручылар – Хәрәкәтнең җирле бүлекчәсе, район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге иң активларга значоклар һәм грамоталар тапшырдылар.

– "Президент белән бергә" – "Спортивный Татарстан" республика акциясе Нурлатта яшь һәм урта буын вәкилләрен аеруча кызыксындырды, – ди район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Әнәс Нәбиуллин. – Спортның отжимание, гер спорты, урыннан озынлыкка сикерү, алга чүгү төрләре буенча 250 кеше үз көчен сынады. Нәтиҗәләр дә сөенерлек.

Хезмәтне ярату, йолаларны саклау, кунакчыллык, шатлык уртаклашуга корылган бәйрәм 10нан артык мәйданда төрле күңел ачулар белән дәвам итте. Балалар шәһәрчегендә уеннар, спорт-күңел ачу чаралары гөрләде, мәйданда якташларыбыз һәм республиканың танылган артистлары - Разия Гайнуллина, Рамил Мифтахов, Фирдүс Тямаев, Радик һәм Ралия Шәрипҗановлар, Замирә Гәрәева, "Мирас", "Шанкаров" ансамбльләре һәм районыбыз үзешчәннәре чыгыш ясаса, балалар арасында "Күңелле карусель" балалар җыры фестивале узды. Традицион фестивальдә быел районның 17 мәктәбеннән биш номинациядә яшь талантлар катнашты. Район сабантуенда биш ел рәттән әтәче алган Рәсим Бакировтан беренчелек яшьләр кулына күчте, әтәч Киеклегә "очты": аны Рифат Әбделвәлиев алды.

Бәйрәмнең зур масштабларда узуы нурлатлылар күңеленә хуш килде.

– Бәйрәм бик матур, - ди нурлатлы Фәридә Әнлиуллина. - Быел милли бәйрәмебезнең бизәлеше дә, программасы да үзенчәлекле. Сабантуй очрашу - күрешү урыны да әле ул. Бүген чит шәһәрләрдә яшәүче сыйныфташлар белән күрештек.

– Сабан туе гади халык ял итсен өчен эшләнгән, - ди Татьяна Спасова. – Бәйрәмне оештыручылар һәр катлам өчен тырышканнар. Мәдәни, спорт чаралары, сәүдә рәтләре, ат чабышлары, көрәш... Оештыручылар районыбыз территориясендә яшәүче һәм эшләүче халыкның хезмәт һәм көнкүрешен чагылдырган почмакларга кадәр тәкъдим иткәннәр. Рәхәтләнеп ял иттек.

Нурлат җирендә старт бирелгән милли бәйрәмебез икенче көнне районның 4 – Киекле, Әлмәт, Биккол, Кычытканлы авылларында да узды.








# Берьюлы ике тапкыр батыр калды



**Сабантуйның көрәш бәйгесе келәмгә йөздән артык спортчыны җыйды.**

Оештыручылар исә яшьләрнең активлыгына сөенүләрен яшермәделәр. "Бүген яшьләрдән илледән артык көрәшче җыелды, алар җиде үлчәү категориясендә бил алышты. Хәтта көрәшне ике келәмдә алып барырга туры килде", – ди ярышларның баш хөкемдары Фәнил Гайнуллин.

Быелгы бәйгедә исә нурлатлылардан тыш, Казан, Чирмешән, Димитровград һәм башка шәһәрләрдән килгән пәһлеваннарны да күреп була иде. Әнә, Казаннан килгән дөнья чемпионы, тагы әллә никадәр титуллар иясе Илнар Әхмәтҗановны Нурлат халкы күптән үз итте инде. "Сезнең Сабантуйларда берничә ел катнашам инде, биредә көч сынашып карар көрәшчеләр җитәрлек, аннан тамашачы да көрәшне аңлый һәм спортчыларның тырышлыгын гадел бәяли белә. Минем Нурлатта персональ җанатарларым да бар инде хәзер", – ди Илнар. Хәер, күп еллар көрәшне тамаша кылган тәҗрибәле җанатарның йөрәгенә якын үз көрәшчесе була – Нурлаттан Газинур ага Гарипов шулай ди. "Үзем, мәсәлән, бертуган Гозәеровларның, Илфат Гыймадиевнең көрәшүен яратып күзәтәм. Быел тагы бер яшь көрәшчебез Алмаз Мостафинның осталыгына сокланып утырдым. Чак кына абсолют батыр булмый калды бит", – ди ул. Чыннан да, абсолют батыр исеме өчен көрәштә Алмаз Мостафин баштагы минутларда көндәше, күптапкырлар Сабантуй батыры, спорт остасы Илфат Гыймадиевны отып барды. Әмма сөлгеләрне бәйләп алышка күчкәч, Илфат, кем әйтмешли, үзенең "коронный номерын" күрсәтә алды: төп вакыт тәгәлләнергә берничә секунд калып барганда, ул чиста җиңүгә ирешә һәм Нурлат сабантуйларының алтынчы тапкыр абсолют батыры исемен яулады. Әмма төп алыш алда иде әле. Эш шунда, быел сабантуйлар тарихында беренче тапкыр суперфинал үткәрелде. Әлеге супералышта Казан кунагы, дөнья чемпионы Илнар Әхмәтҗанов белән Илфат Гыймадиев очраштылар. Биредә инде тамашачыларга ике оста спортчы татар көрәшенең матурлыгын бар яклап күрсәтә алдылар. Әнә бит, икесенә дә җиңү бирергә, дип шаулашып та алдылар. Көрәш исә Илнарның бер-бер артлы алымнары белән башланды, әмма бу көрәш Илфатның әлеге дә баягы "коронный өлешенә" кадәр генә сузылды: сөлгеләрне бәйләүгә һөҗүмгә күчкән Илфат алты минутка сузылган "ел алышында" өстен чыкты. Шул рәвешле, Илфат Гыймадиев бер Сабантуйда ике тапкыр абсолют батыр исеме яулады.

Барлык җиңүчеләрне һәм призерларны район башлыгы Равил Кузюров котлады. Һәркемне матур көрәш белән сокландырган Илфат Гыймадиевка һәм Казан кунагы Илнар Әхмәтҗановка аерым рәхмәтләрен җиткерде.

*Сабантуй темасының дәвамы – 5нче биттә.*

*Сабантуй темасының дәвамы – 5нче биттә.*

**Бәйрәмнән репортажны Зилия ӘКСАНОВА һәм Илназ МӨБАРӘКШИН әзерләделәр. Авторлар фотолары.**





**Сабантуйдан фотоларны nurlat-tat.ru сайтыннан карый аласыз.**

# КӨН АРТЫННАН КӨН

ЭШЛЕКЛЕ ДАИРӘ

## Төрек инвесторлары килеп китте



Автор фотосы

ТӨРЕКЛӘР КИРПЕЧ БАЛЧЫГЫН АНАЛИЗГА АЛДЫЛАР

**Узган атнада Нурлатта дустанә һәм эшлекле визит белән Төркиядән Җәйһан шәһәре мэры урынбасары Сәләхетдин Гуляр, OZALSAN авыл хуҗалыгы техникасы җитештерү компаниясе директоры Озджан Озал булып киттеләр.**

Җәйһан шәһәре белән Нурлатның дуслыгы 2012 елдан бирле бара. Агымдагы елда гына да делегация икенче тапкыр Нурлатка килә инде. Төрек дусларыбыз Нурлатның икътисади потенциалын һәм сәнәгатен өйрәнү, районда яңа мәйданчыклар булдырып, алга таба инвестицияләр кертү максаты белән килә. Бу юлы аларның эшлекле визиты Нурлатта кирпеч заводы төзелеше, аның проекты буенча фикер алышу белән бәйле иде.

Кунакларны каршы алган район башлыгы Равил Кузюров Нурлаттагы яңалыклар - үзгәрешләр белән таныштырды, район тормышы турында кыскача мәгълүмат бирде.

Аннан делегация Равил Әфраимович һәм район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Руслан Морадыймов озатуында кирпеч заводы төзеләчәк урынга чыкты. Төрек инвесторлары район җитәкчелеге белән яңа завод проектын карадылар, әлеге урындагы балчыкны химик анализга алдылар. Аннан эшлекле аралашу сәнәгать мәйданчыкларында дәвам итте. Республикада иң бай тарихы булган шикәр заводын да төрек инвесторлары кызыксынып карадылар. Кунакларны "Южная" агрофирмасының терлекчелек комплексы да кызыксындырды. Икенче көнне Төркия кунаклары милли бәйрәмебез Сабан туенда катнаштылар.

Зилия ӘКСАНОВА

ПЕЧӘН ӨСТЕ

## Кырлар батыры Илгиз

**Район хуҗалыкларында азык әзерләү тулы куәтенә бара. Кичәге көнгә 772 тонна печән, 5914 тонна сенаж һәм 4 тонна яфрак азык әзерләнгән.**

"Нурлат сөте" хуҗалыгы механизаторы Илгиз Гыймадиевка да бу көннәрдә тик торырга туры килми, чөнки биредә печән әзерләүнең кызган чагы. Хәер, Илгиз турында сүз барганда, бу көннәрдә дип әйтү дөрес тә булып бетмәс. Чөнки механизатор ел әйләнәсе кырдан кайтып керми – яз башыннан чәчүдә булды, азык культураларын чәчеп бетерү белән хуҗалыкта печәнгә дә төшәргә өлгерделәр, һәм ул "чәчкеч"тән "чапкыч"ка күчеп утырды. Аннан уракта игеннәрне урып-җыюда да катнашачак. Эше шулай тынгысыз булса да, яратып башкаргангамы, һич тә зарланмый.

– Беренче тапкыр тракторга әле армиягә киткәнче үк, 1977 елда утырган идем. Хезмәт итеп кайткач та кырга чыктым. Башта җирле колхозда эшләдем, "Нурлат сөте" җәмгыяте оешкач, шунда күчтем, - ди ул. Үзгәреш елларында да авыл хуҗалыгы тармагыннан китмәвенең сере дә шул авыл тормышын һәм хезмәтен үз итүеннән. Тырыш хезмәте район һәм республика җитәкчелегенең бүләкләренә дә ия булган.

– Иң тырыш механизаторларыбыздан ул безнең. Кайда гына эшләсә дә, сыната торган түгел, - ди аның турында хуҗалык җитәкчесе Вәзир Сәгыйров та.

Илгиз Гыймадиев – үрнәк гаилә хуҗасы да әле. Тормыш иптәше Рәзинә ханым белән Югары Нурлат микрорайонында яшиләр, ике ул тәрбияләп үстергәннәр. Менә быел да уллары Илфатның Нурлат Сабантуенда батыр калуына шатландылар. Аталыуллы Гыймадиевләр әнә шулай басуда да, көрәш мәйданында да сынатмыйлар.

Лилия МӨБАРӘКШИНА



Автор фотосы

## Гасыр баласы – "Нурлат" телевидениесе



Автор фотосы

КОЛЛЕКТИВНЫҢ ҮЗӘГЕ ТРАДИЦИЯЛӘР ТУДЫРДЫ

**2000нче елдан яшәеш алган "Нурлат" ТРКсы бүген үзенең 15 еллыгын билгеләде.**

Аякка басу, ныгу, үсү чоры–бу вакыт өземтәсенә куелган бурычны хезмәттәшләребез бер дигән итеп үтәп чыктылар. Ә соңгысы–үсү дигәне даими процесс, чөнки иҗатта камиллекнең чиге юк. Камиллек дигәнең исә телевидение өчен грамоталар һәм дипломнар белән генә үлчәнми (бусы алар өчен күптән ирешелгән үр), ул–әчке канәгатьлек, рухи бөтенлек, туктаусыз яңалыкка, киңәергә омтылу. Ике ел элек, мәсәлән, алар яңа телемачта күтәртеп, кабул итү диапазонын киңәйттеләр, узган ел "Летай" Ай-Пи контентына һәм "Таттелеком"ның кабель челтәренә кереп, теле - тамашачылар аудиториясен арттырдылар, студияләрен яңарттылар.

–Телевидение–техника һәм иҗатның синтезы ул,–ди "Нурлат" ТРКсы директоры Резеда Гиняева, – Уңышлы эшләү өчен һәр ике як та һөнәрмәнләрчә тупланган булырга тиеш. Бүген телевидение коллективының 50 процентын беренче көннән эшләүче кадрлар тәшкил итә, традицияне алар тудырды. Һәр килгән яңа хезмәткәр үз яңалыгын өсти тора.

Эшне заманча оештыру дигән төшенчә хәзер иҗат белән бергә финанс ныклыгына ирешүне дә күздә тота, чөнки һәр яңару эшләп тапкан акчага башкарыла бит. Шуңа да реклама базарында ышанычлы партнер булу өстендә дә күп эшлиләр алар. Ә алда әле – башланмаган еллар, дистәләгән проектлар, иҗади планнар. Бүген телетамашачыларга исә "Нурлат" ТРКсы 2000 елның 10 июнендәге иң беренче тапшыруын карарга тәкъдим итә. Чагыштырып, үсешне күрергә һәм ихластан сөенергә менә дигән форсат булачак бу!

**Бәйрәмегез белән, дуслар!**

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

ХӘБӘРЛӘР

### ПРАЙМЕРИЗДА КАТНАШУЧЫЛАР ФУТБОЛ УЙНАЯЧАК

12 июнь – Россия көнендә "Бердәм Россия" партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе шикәрчеләр микрорайонындагы стадионда мини-футбол матчы үздыра. Анда районда гөрләп үткән праймеризларда катнашучылар белән сайлаучылар һәм журналистлардан торган командалар очрашачак. Бу көнне мондый матчлар бөтен республика буенча узачак. Бердәмроссларр көндезге 10да барлык нурлатлыларны да стадионда прайм-лига матчына көтеп калалар.

### БИККОЛДА ЮЛ ТӨЗИЛӘР

Бу көннәрдә Биккол авылы урамнарында трактор тавышы тынып тормый. Биредә үзәк урамнарда НУАДлылар юл салу белән мәшгуль. 1,5 километр озынлыгындагы юл авыл урамнары буйлап аркылы узачак һәм Үзәк урам буйлап мәчеткә тоташачак. Авыл юлын төзү торак пунктларның урам-юл челтәрләрен норматив хәлгә китерү республика программасы буенча алып барыла. Районда быел әлеге программа буенча Илюткино, Мамык, Чишмә һәм Кәкре Атау авылларында да яңа юллар барлыкка киләчәк.

Юлчылардан күреп, бикколлылар авылның Ленин урамының бер өлешендә үз көчләре белән юлларны ремонтлый башлаганнар. Ремонтка төзелеш калдыкларын кулланалар, бу эштә Ленар Закиров, Рамил Әхмәтшин, Илдар Шәйдуллов, Вахит Вилданов һәм авылның башка егетләре башлап йөриләр икән.

### ОФИС БУЛАЧАК

Бу көннәрдә шәһәрнең үзәк майданының архитектур йөзен инде күптәннән бозып торучы элеккеге ведомстводан тыш сак бүлеге бинасын сүтә башладылар. Һәм, әлбәттә инде, нурлатлыларны бу урында нәрсә төзиячәкләр дигән сорау борчый. Сорауга район башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы Наталья Крайнова ачыклык кертте.

- Бу бина һәм аның җир участогы сатуга куелган иде. Сатып-алулар үтте һәм аны физик зат отты. Биредә ул административ-офис бинасы төзергә ниятли, - диде ул.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

### МЧС АКЦИЯ ҮТКӘРДЕ

28 майдан 6 июньгәчә Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы "МЧС – имин балачак өчен!" дип аталган Бөтенроссия акциясе үздырды. Узган атнада 73нче янгын часте хезмәткәрләре акциягә кушылып, "Чияле Алан" балаларны сәламәтләндерү лагеренда эвакуация буенча дәрес үткәрделәр, монннан тыш, балаларга иминлек кагыйдәләре, беренче ярдәм күрсәтү турында сөйләделәр, янгын техникасын күрсәттеләр, экстрен службаларның телефоннарын хәбәр иттеләр.


### ИМТИХАННАР ДӘВАМ ИТӘ

8 июньдә Нурлатның 181 чыгарылыш укучысы сайлап алынган фәннәр – җәмгыять белеме һәм химиядән Бердәм дәүләт имтиханы тапшырдылар. Чыгарылыш укучылары мәҗбүри фәннәр – рус теле һәм математикадан, ирекле фәннәрдән – география һәм рус әдәбиятыннан БДИ тапшырды инде. Нәтиҗәләр уртачадан югары, аеруча 2, 3, 8нче мәктәпләр чыгарылышлары зур баллар белән сөендерделәр.

Зилия ӘКСАНОВА

БӘЙРӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

# Аргамаклар күп, юртаклар да арта


Автор фотосы

**Ат спорты ярышларында илледән артык юртак һәм аргамак көч сынашты. Алар арасында тугыз чабыш уздырылды.**

Шунысы игътибарга лаек, быелгы Сабантуенда юртаклар да шактый җыелган иде. Мисал өчен, Социалистик Хезмәт Герое Валентин Ефимов исемендәге призга уздырылган заездда гына да тугыз юртак узышты. Тәүге тапкыр уздырылучы бу заездны "Актай" җәмгыятенең Парфеноны отты (җайдагы Дмитрий Булыгин). 3 яшьлек юртаклар арасындагы узышта да әлеге җәмгыятьнең шул ук җайдак иярләгән Ламанш туры айгыры баш килде. Ә Орлов юртаклары өчен оештырылган заездда "Ягуар" спорт клубының җайдагы М.Маслов булган Подвигы җиңү яулады. Дүрт яшьтән өлкәнрәк юртаклар арасындагы 2400 метрлы дистанцияне беренче булып "А.Сафин" КФХсының Звездопад кара айгыры үтте (җайдагы – Владимир Рачин). Моннан тыш, призерлар арасында нурлатлы Григорий Шугаев һәм "Татбурнефть"нең, "Сөләйманов Ә.И." хуҗалыгының, Солтан Шәйхуллин юртакларын күрергә була иде.

Аргамаклар арасында исә алты чабыш үтте, һәм бередә Нурлаттан тыш, Ульян, Аксубай, Чистай атлары да бар иде. Мәсәлән, Ульян өлкәсенең Крупская исемендәге комплексы елның-елында Нурлат сабантуена килүне гадәт иткән. "Үземнең беренче генә килүем әле, әмма бирердәге ат чабышлары турында еш ишеткәләп тордым. Менә быел үзем дә килеп карарга булдым, тик беренче коймак төерләрәк булып чыкты: дүртенче генә килә алдым. Киләсе елга ныклабрак әзерләнергә туры килер инде", – ди әлеге комплексның Колчестер туры айгыры җайдагы Ринат Нигъмәтуллин. Ә призлы урыннарның күпчелеген Нурлат аргамаклары яулады. Мисал өчен, 2 яшьлек чиста токымлы аргамаклар арасында беренче булып Нурлат ат заводының Руслан Ризатдинов иярләгән Марлин җирән айгыры килде. Өч яшьлек һәм аннан өлкәнрәк чиста токымлылар арасында уйнатылган Нурлат шәһәре призын "Нурлат сөте" ОООсының Голден Каскад туры айгыры отты (җайдагы – Э.Кунакбеков). Ярымтокымлы атлар Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре хөрмәтенә үткәрелгән чабышта көч сынаштылар һәм монда беренче урынны "А.Сафин" КФХсының Сухарь җирән биясе алды (А.Храмов). Шулай да күпсанлы тамашачыларның иң яратып карый торган чабышлары, гадәттә, җирле токымлы атлар арасындагы узыштыр, мөгаен. Быел андый чабыш икәү булды. Аның беренчесендә җиде аргамак көч сынашты. 2400 метрлы араны "А.Сафин" КФХсының жокей В.Горбунов иярләгән Адмирал туры айгыры беренче булып үтте. "Авыл егетләре" призына уздырылган соңгы чабышны "Сөләйманов Ә.И." хуҗалыгының Флора туры биясе отты (җайдагы Г.Никитин). Җирле атлар арасында "Южная", "Агромир" СИ, "ИРС" хуҗалыклары, Аксубай районы аргамаклары да катнашты. Җиңүчеләрне һәм призерларны ярышларның баш хөкемдары – районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Ислам Сафиуллин котлады.

Илназ МӨБАРӘКШИН


САБАНТУЙ КУНАКЛАРЫН ИКМӘК БЕЛӘН КАРШЫ АЛДЫЛАР

# Сабантуйда ГТО да тапшырдылар

**Якшәмбе көнне Биккол авылы Сабан туе да авылның яше, картын бергә җыйды.**

Бикколлылар Сабантуйны быел да көтеп алдылар. Әле бәйрәмгә берничә көн кала авыл урамнары буйлап мәдәният йорты хезмәткәрләре, яшьләр һәм балалар уен-җырлар белән бүләк җыйды, күпләр иганәчелек ярдәме күрсәтергә ашыкты. Бәйрәмдә соңгыларына авыл җирлеге башкарма комитетыннан Рәхмәт хатлары да тапшырылды.

Сәхнә түренә чыгып бүләк алучылар арасында юбилейларын билгеләп үтүчеләр дә, гаилә туйларын үткәрүчеләр дә, хәтта төрле бәйгеләрдә актив катнашкан авыл укучылары да бар иде. Әнә, 55 ел тату гомер кичергән гаиләләр арасында Сөләймановлар, Вафиннар, Шәкүровлар, Билдановлар бар. Ә Мөнҗия һәм Вәзир Закировлар ярты гасыр тату гомер кичерәләр, тагы 5 гаилә көмеш туйларын билгеләп үтә икән быел. Ә менә Әсхәт Сәфәргалиевка сәхнә түренә хәтта ике тапкыр чыгарга туры килде: юбилее өстенә, тормыш иптәше Хафизә белән гомер корыларына 25 ел да тулган икән быел.

Мәйдан исә уеннардан гөрләп торды. Көянтә белән су ташудан хатын-кызлар гына түгел, ир-егетләр дә читтә калмады, кемдер аркан тартышуда катнашты, кемдер капчык сугышына керде... Быел оештыручылар "Президент белән бергә" хәрәкәтенә кушылып, ГТО нормалары тапшыру өчен спорт мәйданчыгы да булдырганнар иде. Бу көнне 16 кеше спортның берничә төре буенча үзләрен сынап карадылар, һәм иң яхшы күрсәткечләргә ия булучылар Сабантуй бүләкләре дә алды.

– Киләсе елларда да ГТО нормалары тапшыруны традициягә кертергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килдек. Бу авыл яшьләрен спортка, сәламәт яшәү рәвешенә тартуның үтемле бер юлы, – ди авыл җирлеге башлыгы Рамилә Әхмәтшина.

Ә ир-егетләргә, әлбәттә инде, көрәш мәйданында үзләрен күрсәтергә җай чыкты. Быел да баш батыр исеме өчен көрәш 11нче сыйныфны тәмамлаган Радик Шарапов, Арслан Вилданов һәм Рузәл Сәфәргалиев арасында барды. Абсолют җиңү исә Рузәл Сәфәргалиевка насыйп булды, аңа тәкә белән бергә тузан суырткыч тапшырдылар.

Сәхнәдә авыл гына түгел, район үзешчәннәренең дә чыгыш ясавы бәйрәмгә үзенчәлекле төсмер бирде, мәйдан күп сыйныфташлар өчен дә очрашу урыны булды, тирә-як авыллар халкын да сыйдырды. Теләүчеләрне самавыр чәе, кайнар коймак белән сыйладылар, сәүдә рәтләре гөрләде, шашлык тәкъдим ителде. Ә бикколлылар оештыручыларга рәхмәт әйтеп, киләсе елда да Сабантуй мәйданында очрашырга дип сүз куешып аерылыштылар.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

# Кизләүдә өч тәкә уйнатылды


Автор фотосы

БЕР САБАНТУЙДА ӨЧ БАТЫР

**Узган якшәмбедә Кизләү авылы Сабантуена мең ярымлап кеше җыелды. Бирегә күрше-тирә авыллардан, чит шәһәрләрдән кайтучылар да бихисап иде.**

– 26 ел авылда милли бәйрәм үткәрелмәгән булган бит, - ди Лениногорск шәһәрендә яшәүче Кизләү авылы килене Гөләндәм Кәбирова. – Авылда бәйрәм була дигән хәбәрне ишетү белән "кош токкандай" сөенеп кайттык. Ә урыным күргез, Киекле белән Кизләү арасындагы заманында бәрәнге утыртылган җирләрдән Сабан туе өчен бер дигән алан килеп чыккан.

– Кизләү авылы халкы үзенең бердәмлеген бик күп авылларга үрнәк итеп күрсәтте, - ди тамырлары белән әлеге авылдан булган Шамил Кашапов. – Теләк булгач, бәйрәме дә оеша, кешеләре дә кайта икән.

Быел чик сакчылары бәйрәмендә туган Сабан туе үткәрү идеясен авыл халкы бик тиз күтәреп алган.

– Авылыбызда икенче Сабан туе үткәрәбез бит инде, - ди Киекле авылы җирлеге башлыгы Рәфис Ганиев. – Күптән түгел балалар Сабан туе да халыкның актив ярдәме белән гаилә бәйрәме булып узды. Бүгенге бәйрәмгә дә кем ничек булдыра алды – шулай ярдәм итте. Кайсы атәч китерде, кемдер акчалата ярдәм итте, бәйрәмебездә көрәшчеләргә дип өч тәкә булдырылды әнә.

Чараны ачкан һәм район башлыгы Равил Кузюровның сәламнәрен юллаган аның урынбасары Флүра Ногманова әлеге традициянең дәвамлы булуын теләде. Корьән сүрәләре укып башланган милли бәйрәм яше-картының очрашу-күрешү урыны булды. Кизләүлеләр Сабан туен барлык шартларына китереп оештырган иделәр. Авылның иң өлкән кешеләре 87 яшьлек Минҗиһан Садыйкова, Нәҗип Әсәров та хөрмәтләнде. Күп балалы, иң еракган кайтучы кунаклар, яшь гаилә коручылар да игътибарсыз калмады, юбилярларны да котладылар.Атәч тә ерак "очмады: авыл егете Рифат Әбделганиевка насыйп булды. Шулай да иң мавыктыргыч мизгел милли көрәш иде. Бу көнне укучылар арасында Руслан Мортазин, яшьләрдән Солтан Шәймәрданов һәм Зөлфәт Сөнгатуллин батыр калдылар. Иганәчеләр әзерләгән өч тәкә Сабан туе батырларына тапшырылды. Ат чабышлары, милли уеннар – көянтә белән су ташу, чүлмәк вату, аркан тартышу, капчык сугышы, гер күтәрү, капчык киеп чабу, көрәш, концерт программасы, сәүдә рәтләре белән үрелеп барган бәйрәм кичкә кадәр сузылды.

Зилия ӘКСАНОВА

КИЧӘГЕ ПОЧТАДАН

## КӨТҮ БУЛГАЧ, КҮҢЕЛ ТЫНЫЧ

Яңа Әмзә авылы тирәсендә мул үләнле көтүлекләр җитәрлек. Шуңа да авыл көтүен кайда йөртергә дип аптырыйсы юк. Терлекләр иртә таңнан кичкә кадәр шифалы үләннәр белән сыйланып кайткач, сөтне дә мул бирә. Авылда терлек асраучылар шактый, көн саен көтүгә 100гә якын терлек йөри. Шуңа да көтүчеләрнең җаваплылыгы зур. Көтүне исә авыл халкы җыенда быел да чиратлап көтәргә дигән карар кабул итте. Соңгы берничә елда көтү чиратын әйтүне Рәкыйбә Ногманова тәртипләп алып барган иде, быел бу җаваплы эшне Румия Мифтахова йөкләделәр. Румия дә эшне җайлап оештыра, кешеләр белән дә уртак телне тиз таба. Шуңа да авыл халкының көтү чираты өчен дә, терлекләре өчен дә күңеле тыныч.

Сания ФӘТХЕТДИНОВА, Яңа Әмзә авылы.

